ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 25 » гыйнвар 2019 ел** **№ 22**

**«Балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларының матди-техник базасын үстерү һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» Башкарма комитетның 2016 елның 1 мартындагы 206 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алына торган керемнәр күләмен һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә юнәлдерелә торган чыгымнар күләмен арттыру максатларында, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, Арча район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларының матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 1 мартындагы 206 номерлы карарына (Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 20 гыйнварындагы 20 номерлы, 2017 елның 31 августындагы 735 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Балаларга өстәмә белем бирүче «Арча» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенә 1 нче кушымтада

- Фитнес таблицасын (тренер белән дәресләрне) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**Фитнес (тренер белән шөгыльләнү)**

| Килүчеләр | аена дәресләр саны | Дәвамлылык 1 дәрес, сәгать | Бәясе, сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Абонемент | Тапкыр |
| Өлкәннәр | 8 | 2 | 500 | 100 |
| 18 яшькә кадәр балалар | 8 | 2 | 400 | 60 |
| Көндезге уку формасы студентлары | 8 | 2 | 450 | 70 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин